**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№709**
**13.02.2019**

Башкарма комитетның «Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирү турында» 2016 елның 12 июлендәге 3538 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирү турында» 2016 елның 12 июлендәге 3538 нче карарына (Башкарма комитетның 2016 елның 16 сентябрендәге 4814 нче, 2017 елның 20 октябрендәге 6380 нче, 2018 елның 25 декабрендәге 7764 нче карарлары редакциясендә), 5 нче кушымтаны кушымтада каралган редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы И.Н. Галимовка, Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы Р.М. Усмановага, Комсомол районы хакимияте Башлыгы А.И. Кисловка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2019 елның 13 февралендәге
709 нчы карарына
кушымта

Башкарма комитетның
2016 елның 12 июлендәге
3538 нче карарына
5 нче кушымта

Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга
физик затлар мөлкәтенә фактта түләнгән салым күләмендә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләве бирү буенча шәһәр Башкарма комитеты Автозавод районы хакимиятенең комиссия
составы

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Усманова Р.М. | - комиссия рәисе, Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы |
| 2. | Әлмөхәммәтова Е.Ю. | - комиссия рәисе урынбасары, Автозавод районы хакимияте Башлыгы урынбасары, халыкка социаль ярдәм күрсәтү бүлеге башлыгы |
| 3. | Сабирҗанова Г.Ф. | - комиссия секретаре, Автозавод районы хакимияте халыкка социаль ярдәм күрсәтү бүлегенең баш белгече |
| | комиссия әгъзалары: | |
| 4. | Әхтәмова Г.Р. | - Автозавод районы хакимияте халыкка социаль ярдәм күрсәтү бүлегенең әйдәүче белгече |
| 5. | Мурсякова С.В. | - Башкарма комитет карамагындагы опека һәм попечительлек бүлегенең әйдәүче белгече |
| 6. | Зенковец О.С. | - Башкарма комитетның финанс идарәсе бюджет бүлегенең баш белгече |
| 7. | Искәндәрова Л.К. | - Автозавод районы хакимияте халыкка социаль ярдәм күрсәтү бүлегенең әйдәүче белгече |
| 8. | Шутенко А.Г. | - РФ Пенсия фондының ТР Яр Чаллы шәһәрендәге идарәсе (районара) ДУ социаль түләүләр бүлеге башлыгы (килешенү буенча). |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова